**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.07.2025 № 774

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннары бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 01 ноябрендәге 1045 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның  26 гыйнварындагы 42 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе Торак кодексы, торак урынны махсуслаштырылган торак фондына кертү кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннары бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның  01 ноябрендәге 1045 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннары бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә (1нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.6 пунктта. «унитар предприятиеләр» сүзләрен «коммерциягә карамаган дини оешмалар»сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. 2.2 пунктында. "җирле үзидарә," сүзләреннән соң «коммерциягә карамаган дини оешма» сүзләрен өстәргә.;

1.3. 2.2 нче пунктның 4 нче подпунктында. "муниципаль унитар предприятиеләр "сүзләрен" коммерциягә карамаган дини оешмалар»сүзләренә алмаштырырга.;

1.4. 2.10 пунктында. «унитар предприятиеләр» сүзләрен «коммерциягә карамаган дини оешмалар»сүзләренә алмаштырырга.

2. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннары бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның  01 ноябрендәге 1045 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районының махсуслаштырылган муниципаль торак фондында хезмәт торак урыннары бирелә ала торган гражданнар категорияләре исемлегенә (2нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. түбәндәге эчтәлекле 10 пунктны өстәргә:

«10. Коммерциягә карамаган дини оешмалар хезмәткәрләренә».

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин